


Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ОКТЯБРЬ * 2016 * КАЗАН

16

Илдар НӘФИЕВ



8–11 нче битләрне кара

АННАН-МОННАН

ИҢФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

● Илон Маскның, бер миллион кешене Марска озату вәгъдәсе бирелгәннән соң, Евросоюзда качаклар мәсьәләсен хәл итү мөмкинчелеге барлыкка килде.

● Рәсәйнең карап-күзәтеп тору комитеты (Роскомнадзор) ислам дәүләте башлыкларына штраф салган: интервью биреп, ИГИЛны искә алганда, алар аның "РФда тыелганлыгын" өстәргә онытканнар.

● Киев әбисе, протест йөзеннән, Порошенкога үзенең печтик кенә булган пенсиясен кире җибәргән һәм җавапка аннан тагын шулай җибәреп торуын сораган.

● Телефончы террорист мэрия бинасына "Самсунг" смартфоны куелганын хәбәр иткән.

● Финанс министрлыгында бухгалтер һөнәре бетәчәген хәбәр итеп куйганнар. Эшкуарлар аптырашта: растрата өчен кем утырырга тиеш була соң инде?

● "Мир" банк карталары барлыкка килгәч, бюджет оешмаларында "Принуждение к Миру" операцияләре башланачак.

● Чиполлино әкиятенең яңа басмасы чыкты. Андагы мөртәт һәм эксплуататор синьор Помидор үз белдеге белән өй җиткергәне өчен Тыква абзыйны өеннән куып чыгарган. Сәбәбе: кадастр паспорты һәм милеккә хокук таныклыгы булмауда икән.

● МВД полковнигы белән булган хәлдән соң, Югары суд, судьяларга попугай кебек: "Минем әлеге полиция хезмәткәренең намуслы булуы турында бернинди шигем юк", дип, такылдап тормаска кушкан.

● Бертуктаусыз поликлиникаларда йөрү сәбәпле, әби медицина фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән.

● Җинаятьчелек кодексында "Зур күләмдә акча кертеп бирмәгән өчен" дигән статья барлыкка киләчәк.

● Университетларда укып чыкканнар өчен эшкә урнашу көннән-көн авырлаша бара — супермаркетларда үзеңә-үзең хезмәт күрсәтү кассалары барлыкка килгән.

● Математика буенча Халыкара Олимпиададан соң, паралимпиада уеннары үтте. Анда безнең илнең данын филологлар яклады.

● Мурманск шәһәренә, Стас Михайловның концертына кеше килмәү сәбәпле, Рәсәйнең мәдәният башкаласы дигән мактаулы исем бирелде.

● "Дом-2"нең барлык дисклар архивын өендә саклаган җинаятьчене судта үзен-үзе белештермәүче итеп таныганнар.


Вячеслав ШИЛОВ

ШОМБАЙ
болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Мин менә нәрсә турында язарга телим. Хәзерге ирләр ниндидер йомыкый, куркак. Менә минем күршене генә алыйк. Телевизордан Малахов тапшыруларын карап, ул менә нинди фикергә килгән: "Хатын-кызлар артык шомарып киттеләр, — ди. – Фатирны алып, урамда ялангач калдыралар..." Мин аны тынычландырырга телим, ә ул һаман үзене-кен тукый: "Хатын белән юлбасар арасында аерма күрмим", — ди...


М. МӘРЬЯМОВА,
пенсионер

КАЗАН

Күршегез ялгыша! – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач. **– Аерма бар. Беренчеләрен без үзебез сайлыйбыз, ә икенчеләре безне сайлый.**


Валентин ДУБИНИН

Илдус АЗИМОВ





«Макияж мәктәбендә без кызларны тыш-тан гына түгел, ә эчтән дә үзгәртәбез...»

«Башкортстанда да татарларның күп төрләре бар...»

«Крепостной правоны юкка гына сүгәләр – ул вакытта гарантияләнгән эш урыннары һәм иртәгәге көнгә ышаныч булган...»

(интервьюлардан)

Ризык белән агуланганда ярдәм күрсәтә белә торган официант кирәк.

Җир эшләре. Лицензияләр һәм рөхсәт кәгазьләре кирәк түгел.

Фигураны кулдан коррекцияләү.

Йортта яшәүчеләр игътибарына! Җылы булмаячак. Авария. Озакка сузылачак уңайсызлыклар өчен гафу үтенәбез. ТСЖ.

(белдерүләр)

Ринат МӘННАН

ТАТАРЛАРЫМА

Әй татарым, бар бит безнең
Менә дигән илебез,
Иң кадерле, иң сөекле,
Матур, газиз җиребез!

Тик бер сорау бимазалый:
Нигә болай итәбез?
Эчә-эчә шайтан суын
Җүләрләнеп бетәбез.

Без — мөселман, иман кылып
Бу дөньяда яшибез.
Хәмер белән дус булырга
Кушмый безгә динебез.

Әй татарым, акылга кил,
Ярамаган җирең юк.
Яшел елан башын борып,
Ташла әле син берүк.

Әй татарым, зинһар сорыйм,
Үзебезне яратыйк,
Данлы, аек халык итеп
Бар дөньяга танытыйк!



Вячеслав БИБИШЕВ

Кәгазь укытучылар

Быел минем бәләкәчем беренче сыйныфка керде. Онытылмас мәктәп еллары улымның ата-аналар тутырырга һәм имза куярга тиешле кәгазьләр алып кайтудан башланды. «Кызык, – дип уйлап куйдым мин, – ә укытучылар нинди хәлдә икән? Алар бит шушы отчётлар, планнар һәм белешмәләр аркасында балаларга вакыт калмый дип зарланалар!»

Укытучылар бүгенге көн педагогикасының серләрен ачарга ашыкмыйлар, тик шулай да шәхси сөйләшүләрдә бу кәгазь ташкынының аларны баштанаяк күмгәнлеге ачыклана.

Башлангыч мәктәпне генә алыйк. Сентябрьдә һәр педагог тематик план дип исемләнгән калын папка тутыра. Ә үзе биш-алты предмет алып бара. Рус теленнән генә – илле бит, өстәвенә, аңлатма кәгазе. Шунда ук контроль эшләр графиклары. Хикмәт шунда – Мәгариф министры тарафыннан расланган планнар инде бар. Ә син менә үз планыңны вакытында тапшырмыйча кара!

Чиновниклар уйлап чыгарган тагын бер нәрсә – контроль-тикшерү материаллары тупланган папка. Анда педагог бөтен уздырылган контроль эшләр, диктантлар, белем нормаларын, биремнәрнең җавапларын кертергә тиеш.

Аннан соң озайтылган көн группасы журналы бара. Монда кулдан тутырылган баланың һәм ата-аналар турында мәгълүматлар, ун битлек тәрбияләү эшләре планы, 15 битлек озайтылган көн программасы. Күп кенә укытучылар өстәмә рәвештә түгәрәкләр һәм махсус курслар алып бара. Һәм бөтенесе буенча да журналлар, программа һәм планнар кирәк!

Мәктәп җитәкчелеге дә кәгазь эше өсти тора. Укытучылар сыйныфларның исемлеген күптөрле вариантларда әзерләргә тиеш. Мәктәп медикларын балаларның исемнәре, туган еллары, полис номерлары, алар беркетелгән поликлиникалар кызыксындыра. Тәрбия эше буенча урынбасар укучыларның мәктәптән тыш нәрсә белән шөгыльләнүләре, алар йөргән түгәрәкләрнең эш тәртибенә кадәр белеп торырга тиеш.

Педагогның һәр гамәленә ата-аналарның язма ризалыгы кирәк: анда манту прививкасы булдымы, өмәдә катнашумы, күмәкләшеп театрга барумы...

Эш әле моның белән генә бетми. Башлангыч мәктәпнең һәр укытучысы «сыйныфның социаль-көнкүреш паспорты»н тутырырга тиеш. Бу исә һәр укучы һәм сыйныф турында тулы мәгълүмат: ата-аналарның эш урыныннан алып, матди халәтенә хәтле. Укучының гаиләсенә барып йөрү бурычы да укытучы җилкәсенә төшә; моның буенча шулай ук отчёт язарга кирәк.

Мәктәп тормышының иҗади өлешен дә читтә калдырып булмый. Атна саен диярлек сыйныфларга күптөрле конкурсларга чакырулар төшерелә. Катнашмыйча ярамый – бу мәктәпнең рейтингына тискәре тәэсир ясый. Ә аларның күпләрендә катнашучылар җыяр өчен ата-аналарны үгетләргә (күп кенә конкурслар түләүле), мөрәҗәгатьләр тутырырга кирәк. Һәр беренче сыйныф укучысына портфолио ачыла, анда мәктәпне бетергәнгә кадәр укучының казанышлары теркәлеп бара. Аның алып барылуы өстеннән, әлбәттә, укытучы күзәтеп бара.

Моңа тагын көндәлек электрон журнал алып бару, дәфтәр тикшерү, дәрескә әзерләнүне өстәгез. Урта һәм өлкән сыйныфларда эш җиңеләйми – моңа тагын Бердәм Дәүләт Имтиханына әзерләнү килеп кушыла...

Менә шулай, кәгазь өемнәре артыннан укытучы баланы күрә дә алмый. Аның укучы белән аралашырга вакыты калмый. Мондый хәлдә нинди белем бирү турында сүз баруы мөмкин соң?

Люция МОСТАФИНА



Валентин **ДУБИНИН**

Александр АЛЁШИН



Николай ВОРОНЦОВ





• • •

– Уйлавымча, мин, ниһаять, финанс тотрыклылыгына ирештем!

– Ничек?

– Акчам булмады, хәзер дә юк, һәм беркайчан да булмаска охшаган...

• • •

Ришвәтчелек сакланышы законын ачканнар:

–Ришвәтчелек юктан бар булмый, беркая да китеп югалмый, бары тик бер кабинеттан икенчесенә генә күчә.

• • •

Директор производство киңәшмәсе үткәрә:

– Кем дә кем алдан планны үти, миннән – шоколад!

– Шеф, акчалата түләсәгез иде...

– Башла-а-а-анды! Мин бит инде шоколадлар сатып алган идем!

• • •

Бик зур түрә Р. гастритын дәвалау өчен халык чараларын куллана. Бу ысулны кулланып ул инде Карловы Варыда, Баден-Баденда һәм Европаның күп курортларында булып кайтты!

Офистагы әңгәмә:

– Сезнең компьютер белән эшләрегез ничек?

– Яратмыйм мин аны: утырасың каршысында җүләр кебек...

– Нигә алай дисез?

– Күзләрем дә начар күрә: мин экранда курсорны да юньләп күрмим.

– Күзлек кию ярдәм итмиме?

– Күзлек киеп утыруны да яратмыйм: җүләр кебек утырасың шунда...

• • •

– Әйтегез әле, сезнең ярлы туганнарыгыз бармы?

– Әллә тагы...

– Ә байлары?

– Алары мине күреп тә, ишетеп тә белмиләр.

• • •

Ришвәттә тотылган түрә “Мин түгел, мин түгел!!!” дип кычкыра башлый. Кайтавазы болай ишетелә: “Нишләп башкаларга ярый, ә миңа юк!”



ОТЧЁТНЫ – "ЧАЯН"ГА

Чиновниклар халыктан коточкыч ерак дип, юкка гына әйтәләр. Һәрхәлдә, безнең республикадагыларына бөтен кешелек сыйфатлары хас. Татарстанның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Азат Хамаев Югары Ослан районының эшләнгән эше турындагы отчёт белән танышкач, моны үз күзләре белән күргән. Ялкау хезмәткәрләрнең бөтен документациясе... Арча районы отчётыннан алынган өземтәләрдән төзелгән булып чыккан. Алар хәтта текстның исемен үзгәртергә дә онытканнар. Бу хәлгә чиксез ачуы чыккан министр ялган отчётны "Чаян"га җибәрергә тәкъдим иткән.

КӨТЕЛМӘГӘН СЫЙ

Ростов-Дон шәһәре янындагы Некрасовка хуторында яшәүчеләр җирле хакимият башлыгын сумса белән сыйларга булганнар. Аның эчен... чебеннән ясаганнар. Бу елның җәе ул бөҗәкләргә аеруча "уңышлы" булган. Сәбәбе – җирле кош фабрикасының җитештерү калдыкларын теләсә кая ташлау. Район башлыгы Василий Даниленко нәрсәдер сизенгән, күрәсең, һәм әдәпле генә итеп сыйдан баш тарткан. Тик күтәрелгән проблеманы хәл итәргә сүз биргән. Хутор кешеләре, мәсьәләнең урында хәл ителүенә өметләнмичә, Россельхознадзорга шикаять белән мөрәҗәгать иткәннәр. Анда чебенле сумса җибәреп маташмаганнар, чебен кучләрен видеога төшерү белән чикләнгәннәр.

БУШ СӘЯХӘТ

Зимбабве президенты Роберт Мугабе илнең Рио-де-Жанейродагы Олимпиадада катнашкан бөтен спортчыларын кулга алырга әмер биргән. Бу иң соңгы чараның сәбәбе шунда ки, алар бер генә медаль да яулый алмаганнар. Ил башлыгы башка, файдалырак максатлар өчен тотылырга мөмкин булган акчаларның җилгә очкаnына бик ачуы чыккан. Иректән мәхрүм ителү өстенә, булдыксыз спортчыларга, президент сүзләре белән әйткәндә, "Бразилиягә туристик сәяхәткә" тотылган дәүләт акчаларын кире кайтарырга туры киләчәк.



Михаил ЛАРИЧЕВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ

Шәукәт ГАЛИЕВ

БАКЧАДА ЙӨРИ БЕР БАБАЙ

Бакчада йөри бер бабай
Ияртеп чибәр кызын.
Барып сүз дә кушар хәл юк,
Калдырмый бит ялгызын!
Утка килгән күбәләктәй
Әйләнәм кыз катында.
Карт шунда таяк күтәрә:
– Тимә минем катынга!

Нияз БИШБАЛТА

ГЕЛ 5000 БИРСӘ ИДЕ...

– Өлкәннәр көне белән! – дип,
Мәскәү түрәсе котлый,
– 5000 өстибез гыйнварда, –
Дип әйтергә онытмый...

Нигә гыйнвар ае гына,
Февраль-мартлары кайда?
Пенсионерның ашыйсы
Килә бит һәрбер айда!

Вячеслав ШИЛОВ



Александр КОСМЫЛИН



Искәндәр БОРҺАНОВ

БАЗАРДА

– Вай, какой красивый дэвушка! – дип кычкырып куйды базар милләтле бер ир заты. – Күзләре слива кебек, битләре – персик, иреннәре гүя гранат... Кил монда, гүзәлем, җәлләмәссең...

Чибәркәй, җиләк-җимешләрне карый-карый, бәяләр белән кызыксына башлады:

– Ә нигә шулай кыйммәт? Ун тәңкәгә булса да төшерегез инде...

– Вах, ничек төшерим, ди! Бу бит бакчамның иң шәп сливалары... – дип, тау тургаедай сайрый башлады сатучы.

– Белмим, шәпме, түгелме – тик мин мондый бәягә төрек сливасы алырга җыенмыйм, – дип кырт кисте кыз.

– Ярый инде, бераз төшерәм... Кара син аны, нинди комсыз кыз! Синең күзләрең дә слива түгел, ә биш сумлык тәңкә кебек...

– Ә персикка төшерәсезме? – дип дәвам итте кыз, аның сүзләренә игътибар итмичә.

– Ничек инде? Аларны бит әле үстерергә дә кирәк!

– Сез аны Испаниядә үстергән дип уйларга мөмкин, – дип өзде аны кыз.

– Ә китерергә, сакларга, сатарга? – дип кыза башлады сатучы, товарын үлчәүгә салып. – Бәхәсләшкән була тагын! Битләрең дә персик түгел синең, ә менә шушы йомарланып беткән йөзлек...

– Гранатка да төшерергә зыян итмәс иде, – ди кыю гына кыз, сатучыны тыңламыйча.

– Вай, какой сердитый дэвушка! – дип гаҗәпләнде сатучы. – Бөтенесен дә ал, бушлай ал! Минем нәни балаларымны җәлләмисең икән. Синең иреннәрең дә гранат түгел, ә биш йөзлек акча... Ничек яшәргә була микән шундый хатыннар белән?! Мин сиңа чын күңелдән, ә син...

Кыз сатучы кулыннан фруктлар тутырылган пакетны алды.

– Минем күзләремне, битләремне һәм иреннәремне җимеш белән чагыштырып караганым юк! Контрольная закупка! Мин потребнадзордан – менә документларым...

Вай, какой красивый дэвушка и из потребнадзора! Күзләре слива кебек, битләре – персик, иреннәре гүя гранат...

Җире барның җиме бар

Нәрсә ул ришвәтчелек? Аның нәрсә икәнен белешмә китаплар “сатып алу” дигән латин сүзеннән алынган төшенчә, куркыныч социаль күренеш дип аңлата – хезмәт вазыйфасын шәхси баю максатында куллану. Кайбер илләрдә киң таралыш алган. Ул илләр исемлегенә без дә керәбездер инде — безнең түрәләр дә кәнәфиләрендә болай гына утырмый бит...

Бөркү һавалы шәһәр урамнарыннан ераграк урында йорт салып яшәргә теләүче хәлле гражданнарның саны көннән-көн арта бара. Әгәр дә мөмкинлегең бар икән, иза чиккән тугандашларыңа ничек ярдәм итмисең, ди? Бигрәк тә бу ярдәм өчен көмеш тәңкәләр чылтыравы белән рәхмәт белдерсәләр. Азнакай районы Вахитов авыл җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Мөһсинов та шундыйрак фикердә булган, күрәсең. Авыл җирендә олы кеше, өстәвенә — җирле Совет депутаты! Чәкән авылында җир сатып алырга теләүче С. Халатян атлы бәндә нәкъ аңа мөрәҗәгать иткән дә инде. Тик аның бу теләкне тормышка ашырырга бернинди хокуклары да булмаган. Авылда буш җирләр дә җәйрәп ятмаган. Ләкин шуңа да карамастан, Мөһсинов бу четерекле мәсьәләне хәл итәргә алынган. Һәм тиз арада Каф тавы артыннан килгән мосафир татар илендә җир хуҗасы булып киткән. Әйтергә кирәк, бу мәйдан аңа дәүләт милке җирләреннән бирелгән. Таулар каһарманы, безнең “Рәхмәттән тун тегеп булмый” дигән әйтем белән яхшы таныш булгандыр, әлбәттә. Хәзер олы җанлы чиновникның хуҗалык кенәгәсеннән алып тутырылган ялган өземтә-белешмәнең бәясен тикшерүчеләр ачыклый.

Тагын бер депутат — Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы П. Гаврилов та дәүләт җирләрен өләшү ягыннан бик юмарт булган. 2016 елда, ялган документлар ясап, ул Б. Сибгатов һәм В. Лаптевны җирле иткән. Әлбәттә, коры рәхмәт сүзе өчен генә түгелдер дип уйларга кирәк...

Яңа Чишмә районының Черёмухово авыл җирлеге башлыгы Е. Корнеева да үз карамагына тапшырылган дәүләт милкенә җитәрлек дәрәҗәдә җаваплы карамаган. Шулай ук депутат исеме йөрткән ханым дәүләт җирләреннән үзенә 3700 квадрат метр “өлеш” чыгарган. Тулы хуҗа буларак, ул шулай ук хуҗалык кенәгәсеннән өземтә тутырып, аны түгәрәк пичәт белән раслап куйган. Халык мәнфәгатьләрен яклаучы ханымның дәүләткә китергән зыяны 230 мең сум тәшкил иткән.

Чиновникларның үз белдекләре белән дәүләт җирләрен өләшү очраклары, кызганычка каршы, сирәк күренеш түгел. Соңгы ике ел эчендә генә республиканың Яшел Үзән, Питрәч, Тукай һәм башка районнарында җирне законсыз рәвештә рәсмиләштерү буенча илледән артык җинаять эше кузгатылган. Аларның төп фигурантлары — әлеге дә баягы халык депутатлары...

Айдар СУБАЕВ





ШУЛ УК “БАЛЫК БАШЫ” ТУРЫНДА

Ришвәт дигән нәрсә белән кешелек иң борынгы заманнардан бирле таныш.

– Борынгы Русьта чиновникларның “күңелен күрү” гадәти нәрсә булган. Хезмәт хакы алмаган дәүләт хезмәтчәннәре халыкның сырт итен ашап яшәгәннәр. Бары тик Явыз Иван заманында гына мондый тәртиптән баш тартканнар. Патша хәтта үлем җәзасы да керткән. Дөрес, ришвәт алгандагы “чама белмәгән” өчен генә. Хакимият кешеләрен “оклад”ка Пётр Беренче генә утырткан. Ә “бүләк” алу җинаять булып санала башлаган.

– Дөнья коррупциясенең символы булып Твидның Нью-Йорктагы суд бинасы санала. Җирле хакимият әгъзасы Уильям Твид бу гадел хөкем сараен салдырганда ришвәтне шулкадәр чамасыз алган ки, нәтиҗәдә, йортны төзү Американың Алясканы сатып алуыннан да кыйммәткәрәк төшкән.

– Ришвәт алуның иң оятсыз ысулы белән Зимбабве акушерлары дан казанган. Баланы кабул иткән өчен илдәге уртача еллык хезмәт хакының өчтән беренә тәңгәл сумманы алу өстенә, явыз табиблар бала табучы хатынга тулгак тотканда һәр кычкыру авазы өчен биш доллар штраф салалар.

– Кытайда коррупция белән көрәштә каты чаралар белән беррәттән, көлкеле ысуллар да кулланыла. Йорт стеналарында ришвәтче чиновникларны фаш итүче карикатуралар ясала. Ә тотылганнарын, телевидениедән күрсәтеп, бөтен илгә рисвай итәләр.

– Сингапур – коррупцияне җиңгән бердәнбер илдер, мөгаен. Моның ысулы бик гади булып чыга: башта илнең җитәкчесе Ли Куан Ю үзенең туган-тумачаларын утыртып чыккан, ә аннары чиновникларны “кайнар табага” бастырган. Махсус оештырылган бюро артык иркен яшәүче дәүләт хезмәткәрләрен суд карарыннан башка тоткарлый һәм тенти ала. Шул ук вакытта аларның гаепсезлеген тикшерү органнары түгел, ә гаепләнүче үзе исбатларга тиеш.





ШАКШЫ ГАМӘЛЛӘР

Сездә ничектер, белмим, ә миндә “форма” һәм “погон” сүзләре һәрвакыт тирән ихтирам уята иде. Чын мәгънәсендә пакь күңелле һәм намуслы кешеләр арасында нинди коррупция булсын, ди? Тик кырыс тормыш күрсәткәнчә, мундир белән ватанга биргән ант ришвәткә киртә була алмый икән. Күптән түгел генә шау-шу кубарган Эчке эшләр министрлыгы полковнигы Захарченконың сигез миллиардлык ришвәт алуы турындагы эшне генә искә алыйк.

Бездәге форма кигән ришвәтчеләрнең нәфесе тыйнаграк, дип әйтергә була. Мәсәлән, 19 нчы номерлы Казан төзәтү колониясе башлыгы А. Таҗиев хөкем ителгән берсенең хатынынннан даими рәвештә акча алып килгән. Ике ел эчендә ярты миллион сум җыелган. Шома ханым бу акчаны салкын диварлар артында утырган ире үзен өендәге кебек тойсын дип түләгән. Мондый юмартлыктан режим йомшарту гына түгел — тоткынны өенә кайтарып җибәрерсең! Икенче бер тоткынга ул нәкъ шул турыда ишарәләр ясаган да инде. Ул гына түгел, тикшерүчеләр фикеренчә, Таҗиев аны вакытыннан алда – шартлы рәвештә азат итү өчен уңай характеристика да әзерләгән. Тик мондый “олы җанлылык” элеккеге колония башлыгына бик кыйммәткә төшкән — аның хәзер үзенә колониядә берничә ел уздырырга туры килмәгәе.

Чаллыда МЧС отряды офицерлары — янгынга каршы көрәш хезмәте отряды башлыгы полковник С. Субботин һәм аның урынбасары А. Ящук та мундирларын пычратудан чирканмаганнар. “Саулык” комплексының җәйге лагерьларының әзерлеге турында ялган белешмә өчен алар йөз илле тугыз мең сум алганнар. Аларга ярдәм итәргә Шишмарёв атлы бәндә алынган — янгыннан саклаучылар тиешле сумманы аның фирмасы счётына күчергәннәр. Дөрес, алар алар алынган акчаның бер өлешен үзләренә түгел, ә спорт инвентаре сатып алуга тотканнар. Имеш, үз кесәләре өчен түгел, ә гомуми эш турында кайгырткannар. Нәтиҗәдә, мундир чисталыгы турында аларның башлыкларына кайгыртырга туры килгән — ике коткаручыны да... яшьләре җиту буенча пенсиягә озатканнар.

Ни дисәң дә, шәхси мөмкинлекләреннән файдаланып, акча өчен “яхшы эшләр” кылырга теләүчеләр бик күп. Күптән түгел шундый нәрсә белән суд приставлары Р. Хаҗиев һәм Ф. Зәйнуллин эләкте. Алар түләү өчен берничә закон бозучының эшен ябарга алына. «Клиентлар” белән очрашуга коллегалары Э. Майорова бара. Махсус билгеләнгән урында ул аларга эшне туктату турында документ тапшырып, 200 мең сум ала. Үзенә тиешле 50 меңне кесәсенә салып, калган сумманы Хаҗиевка бирә. Тегесе дә үз өлешен алып, сәүдә үзәге бәдрәфендә Зәйнуллинга йөз мең сум тапшыра. Үзләрен оперативникларның күзәтеп торуы аларның башларына да килми. Хәзер “конспираторлар”ның өчесе дә ришвәт алу турындагы эш буенча уза.

Күргәнебезчә, погондагы йолдызлар намусны да, мундирны да кара таплар төшүдән саклап кала алмый икән. Бигрәк тә пычрак гамәлләре бәдрәфтә кылынган очракта...

Артём СУББОТКИН



Сергей **АНДРИАНОВ**

РИШВӘТТӘН ДАРУ



Тиздән Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Зөлфәт Хәкимнең «Бармы ришвәткә дәва?..» сатирик пьесаның премьерасы булачак. Спектакль төп геройның ришвәтчелектән дару уйлап чыгаруы һәм шуның тирәсендәге ыгы-зыгы турында. Премьера алдыннан безнең хәбәрчебез режиссёр Илгиз Зәйниев белән очрашты.

– Илгиз Газинурович, пьесаның темасы яңа түгел. Инде «Чаян» гына, ришвәтчеләрне рисвай итеп күпме каләм сындыргандыр! һәм менә тагын шушы иске темага мөрәҗәгать итү. Моның сәбәбе нәрсәдә?

– Ә бу тема актуаль түгелмени? Үзегез уйлап карагыз: әгәр дә элекке вакытта ришвәт бирү күпләр өчен оят нәрсә булып саналган булса, хәзер исә бу күренеш кешене беренче көннәреннән үк сагалап тора һәм гадәти нәрсәгә әйләнеп бара шикелле. Үзегез беләсез бит: «кирәкле кешеләр»не майламыйча бик сирәк ата-ана гына баласын бакчага, яхшы мәктәпкә һәм дәрәҗәле вузга кертә ала. Моны күреп, тетрәнеп куясың – кая бара безнең җәмгыять?

– Пьесада сүз нәрсә турында бара?

– Төп герой – ришвәтчелектән дару уйлап тапкан мәктәп укытучысы. Ул үзенең ачышы белән бөтен районны аякка бастыра. Чиновниклар тылсымлы таблетканы башта урларга, ә соңрак акча түләп алырга телиләр. Мондый дару барлыкка килү аларны нигә шулай борчуга салган соң? Чөнки таблетка аларны баю чыганагыннан мәхрүм итәчәк. Тәкъдим ителгән «бүләк»тән кем үзе теләп баш тартсын, ди? Кытлык белмичә, мул тормышта кемнең яшисе килми? Алар өчен ришвәт – эчә торган су, сулый торган һава кебек кирәк. Алар бу дөньяда аннан башка яши алмый. Тора-бара, бөтен район мөгаллимгә каршы чыга. Башкаладан килгән дәрәҗәле комиссия дә тылсымлы таблетканы кулга төшерүне максат итеп куя. Нәтиҗәдә, укытучы протест акциясе оештырырга мәҗбүр була… Кыскасы, монда тамашачыга көләргә дә, уйланырга да урын бар.

– Югары җитәкчеләр булачак спектакль турындагы хәбәрне өнәп бетермәгәнәр, дигән хәбәрләр йөри. Бу дөресме?

– Шәхсән миңа бернинди тәкъдимнәр килмәде. Спектакль өстендә эшне дәвам итәбез, һәм 7 ноябрьдә тамашачыларны премьера белән шатландырырбыз дип өметләнәбез. Үземә калса, минем кайбер театрларның Зөлфәт Хәким пьесасыннан баш тартулары турында ишеткәнем булды. Нигә дисезме? Аларга хакимият тарафыннан басым булгандырмы, юкмы — әйтү кыен. Һәрхәлдә, мондый хәбәрләрнең барлыкка килүе пьеса темасының җитди һәм әһәмиятле булуы турында сөйли.

– «Бармы ришвәткә дәва?..» – сатирик комедия. Сатира ул — яшь аралаш көлү бит…

– Әгәр дә кешенең үз-үзеннән көләргә көче бар икән, димәк, әле ышаныч югалмаган дигән сүз. Җанны дәваларга өмет бар. Ә бу иң мөһим нәрсә. Минем өчен сатира жанры – коррупция шикелле чиркангыч күренешне гротеск алымы ярдәмендә «зур план» белән күрсәтү мөмкинлеге белән әһәмиятле. Гротеск, башкача әйткәндә, ясалма көчәйтү, бөтен нәрсәдә дә – актёрлар уенында да, декорацияләрдә дә, хәтта костюмнарда да булачак. Бу миңа, режиссёр буларак, форма белән уйнау өчен киң мөмкинлекләр тудыра. Тамашачы моны уйнаучы актёрлар арасында таныш исемнәр булуны да уңай кабул итәр дип уйлыйм. Болар – Фәнис Җиһаншин (төп рольне башкаручы), Ирек Кашапов, Рамил Вәзиев, Ләйсән Рәхимова. Спектакльгә музыканы Эльмир Низамов махсус язды.

– Мондый темага алынган режиссёр өчен үзенә дә аны яхшы белергә кирәк бит. Ә сезнең үзегезгә кайчан да булса ришвәт бирергә туры килгәне булдымы?



Вячеслав БИБИШЕВ

– Әйе, бер очрак булды. Ләкин уңышсыз. Анда минем бөтенләй «бирә белмәвем» ачыкланды. Берничә ел элек ничектер машинамда «Окушка»ны узып киттем. Хәтта узып киттем түгел, әйләнеп уздым – ул тизлек тә җыярга өлгермәгән килеш трассага чыгып кына килә иде. Ә «Узып киту тыела» билгесен күрмәгәнмен. Мине инспектор туктатты. Патруль машинасына утыртып, бик озак, вакыты-вакыты белән миңа тирән мәгънәле караш ташлап, кылган һәм кылмаган «гөнаһ»ларымның пунктларын һәм параграфларын санап утырды. Ниһаять ул тынып калды. Мин дә бер сүз әйтмичә аңа карап утырам. Гаишникны бу туйдырды, ахрысы – ул мине, «бәхет хаты» җибәрергә сүз биреп, куып чыгарды. Әйтергә кирәк, соңыннан мин бернинди хат та алмадым. Ләкин шул чакта үзем өчен карар кылдым: беркайчан да, беркемгә дә ришвәт бирмәскә. Сезгә дә шуны киңәш итәм…

Әңгәмәне Айдар СУБАЕВ алып барды.

“Чаян” күнекмәсе

ЙӨЗ УТЫЗ ЖИДЕНЧЕ ТУР



Кемнәрне һәм “ниндиләрне” генә күрмисең ул пляжда! Менә шундыйларны күзаллап, “Чаян”ның фотографияләр конкурсына бер авторыбыз шактый кызык эчтәлектәге сюжет төшереп җибәргән. Без аны Күнекмәбезгә тәкъдим итәргә булдык. Ялгышмаганбыз, байтак кына игътибарга лаек җаваплар алдык.

Бу фотография урнаштырылган “Чаян”ыбыз укучыларыбызга әле барып җиттеме — юкмы икән дип уйлап бетермәдек, Ульяновск шәһәрендә иҗат итүче каләмдәшебез Зөфәр Батыровтан ике төрле вариантта шигъри җавап килеп тә төште.

1. Бу “Чаян”ның шаянлыгы —
Тур артыннан тур булыр.
Бу сурәттә ни күрәбез? –
Мәгънәсе зур булыр:
Ияреп хур кызларына
Әбекәйләр хур булыр.

2. И Ходаем, оҗмахыңда
Бәхетен дә бирә бел.
Хур кызлары урынына
Әби генә бирмә гел.

Активлык күрсәтүегез өчен рәхмәтебезне белдереп үтәбез, Зөфәр дус! Ә менә ерактанрак, Екатеринбургтан килгән шаярту — А. Сафиуллинның күзләре бөтән нәрсә күргән. Ул безнең күңелебезне тәрбияләү йөзеннән, тәртипкә өнди: **“Кагыз, әбидә бар итагать — трусигын рәтли, җәмәгать!“** Әби арты белән алгы планда булгач, аның турында сурәтләүләр һәм уйланулар күбрәк. Әйтик, агъза каплавычлары турында… Моңа Яшел Үзәндә яшәп ятучы философыбыз Галиев Мансур фәнни яктан килгән. (Тикшеренүләрен кыскартып бирәбез.) **“Әбинеке — мулрак һәм матуррак, ләкин очсызрак! Кызларныкы — кечерәк һәм таррак, ләкин кыйбатрак! Әллә миңа да шундыйны алыргамы дип, ул бара уйлабрак”. “Барыгыз, бар, алдыгыздан артыгыз әйбәтрәк!”** — дип, халык әйтеменә якын фраза ыргыткан Түбән Камадан Шәүкәт Шәрәфиев дигән шаяныбыз. Бу юлы күнекмәбездә кызлар сурәте күп. Шуңа күрәдерме моңа ир затлары күбрәк игътибар иткәннәр. Менә шуларның тагын берсе, Чаллыдан Илһам Мортазин болай дип язып җибәргән: **“Алдан бара бер мужик, кызлар уйлый: как дружить!”** һәм шуңа: **“Зонтлар астында буфет — шунда тамак чылатыйк!”** — дип өстәп тә куйган. Төрлечә язалар: **“Әбинең арты кычыта, кашып барганын сизми ни чурта”. “Әби үзе — молодец, кызлары да каратист!”** Монысы – Буадан Искәндәрова Гөлсинә бәяләмәсе. Чистайдагы безне укучы Гәрәй Сафиннан шигъри күзәтү алдык:

Пляжда гел кызлар, әбиләр,
Ә бабайлар монда килмиләр.
Әби кызынырга киткәч,
Экрандагы шәрә кызны
Күзлек киеп күзлиләр.

“Яшьләр артларыннан киләчәкләре атлап килгәнен әле сизми”, — дип бик зур мәгънә кертеп язып җибәргән безгә Хабаровск якларындагы Санбәли бистәсеннән С. Коняшева. Искиткеч яхшы җавапка юлыккан бит безнең әлеге күнекмәбез! Әйе, хөрмәтле журналыбызны сөючеләр! Җиңел шаярту гына булмасын иде бездән бирелгән һәм сездән алынган фотосюжетларда.

Язгыгыз, ялкын балкып торсын җавапларыгызда, шаяртуларыгызда!



Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО



Нәҗия БӘХТИЕВА

МАНЬЯКЛАР ТОРМЫШЫННАН

Кемнәр бу шашканнар? Аларны тышкы кыяфәтләреннән яки гадәти булмаган тәртипләреннән танып буламы? Юк, алар нәкъ безнең кебекләр — төрле яшьтәге һөнәр ияләре, елмаючан яки төксе, буйдак һәм тәртипле гаиләле. Барысы да безнең арада яшиләр.

Ләкин менә ниндидер борынгы гадәтләре аларны өйләрендәге яшереп куйган коралны алып, сиздерми генә сәгатьләр буе агачлар арасында суламый-нитми посып торырга мәҗбүр итә. Мәче башлы ябалакның һәм борчылып кычкырган күкшәнең (кош) тавышы тирә-юньгә шом гына тарата. Юеш томан артында чак кына әйберләр беленеп тора. Маньяклар шул мохиттә тынып, очраклы корбанны көтә.

Коралы булмаган кайберләре, сәгатьләр буе очлы, озын япьле пычагын тотып, гөмбәчеләрдән качып, олы юлдагы машина тавышларына колак салып, урманчылыкта яки якын куаклыкта йөри.

Көннәрнең берендә алар яңадан мәрхәмәтле яки ярдәмчел хезмәттәшләр булып китәләр. Гөмбә тулы кәрзин белән өйгә кайту үзе зур бәхет бит! Менә шундый алар маньякларча шашкын гөмбәчеләр.



Заһир ХӘКИМОВ

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 1909–1913 ЕЛЛАРДА ЯЗГАННАРЫННАН

ГЛАСНЫЙ

Качма, ләкте миңа бу язгы сайлауда гласныйлык,
Югары мәртәбә килде олуглык һәм дә важныйлык.

Керештем әһле ислам файдасын саклар вә якларга,
Яңа көч берлә башладым гырларга вә йокларга.

ХӘЗЕРГЕ ӨЙЛӘНҮЧЕЛӘР

Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар:
“Булыр безнең хатын, булса, йөзе айдай”, — диләр анлар.

Әгәр дә басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

СӘФИЛГӘ КАРШЫ ЯЗАРГА ТЕЛӘГӘН КАЛӘМГӘ

Юк, маташма, и каләм! — калсынчы – шундай юк белән;
Борча атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.

Ни эшең бар? Юкмыни, язсаң, югары нәрсәләр?
Угърашып торма җиһанда иң түбән мәхлук белән!

Та әзәлдән ул сәфилләр үз-үзеннән бетмәдә:
Кауме Нухи — су белән йә кауме Лути — ут белән.

Сипмә конфетти аның төсле сәфилләр өстенә:
Ул хәзерләнгән атарга йөзгә каршы чүп белән.

Сәфилгә — түбән, вөҗдансыз (кешегә).
Угърашып — чуалып, бәйләнешеп.
Та әзәлдән — дөнья яратылганнан бирле.

ГАИЛӘ ТЫНЫЧЛЫГЫ

Әгәр булсын дисәң бер өй эче шау-шу вә җәнҗалсыз:
Ире булса сукыр, ул җитми, – булсын һәм хатын телсез.

ТАТАР МӨХӘРРИРЕНӘ

Яз, ни язсаң да, синең бар – язганыңның нашире;
Ашлыгың үстисә – бир, таярдыр аның гашире.

Тик онытма: бер заман гүргә керер ялгыз башың;
Һичбер булмас яныңда; иптәшең һәм кардәшең.


Барча әгъзаң чиркәнеч һәм куркыныч хәлгә керер;
Уйлаган башың, каләм тоткан кулың бергә черер.

Дөньяда булган кеби язганнарыңның нашире,
Монда да кортлар — синең үлгән тәнеңнең “нашир”е.

Нашире — издателе, китап итеп басучы.
Тайярдыр — хәзердер.
Гашире — уннан бер өлеш алучысы.



Леонид ЕЛЬКОВИЧ, «Чаян» № 16, 1966



– Грипптан дигән була...

Вадим МАЛЯКИН , «Чаян» № 11, 1980

Марсель ГАЛИЕВ

ТӘМ

Кибет киштәләрендә җил уйнаган (1986), юклыкның юклыктан юкка калган дәвере. Язучылар берлегендә уртак кабинетта эшләгән Нәбирә Гыйматдинова белән Марсель Галиев ял арасындагы яңалыклар белән уртаклашалар икән.

— Хатын кичә Мәскәүдән кайтты, — дип, тәмләп сүз башлый Марсель Галиев. — Әйтеп җибәргән идем, “Бородино” ипие, селедка алып кайт, дип…

Пауза озаккарак сузылгач, Нәбирә, түзмичә:

— Алып кайтканмы соң? — дип сорап куя.

Сорауның урынсыз икәнен искәртеп, Марсель Галиев сүзен дәвам итә:

— Кирәк бит, нәкъ шул көнне… Кибеткә сугылсам… Шешәле сыра саталар… Сирәк була торган хәл. Алып кайттым бер шешә. Әзерләдем табынны. Каршымда ярмаланып пешкән бәрәңге дәртле бу чыгарып утыра. Тәгәрмәчләп суган туралган. “Бородино” ипиен өчпочмаклап, юка гына кисәм дә горчица ягам. Өстенә кинзә орлыгы һәм сарымсак сибәм. Ул селедканың симезлеге! Кисеп җибәрәм… эченнән мендәр-мендәр уылдык шуып чыга. Һәр бөртеге тары ярмасы кебек җем-җем килеп тетрәп тора, мин сиңа әйтим! Төрле коралда берьюлы уйнаган музыкантлар була бит, мин дә нәкъ шул халәттә. “Бородино” ипиен кабам, аннары суган тәгәрмәче… Селедка уылдыгы белән бергә… Аннары бәрәңге… Соңыннан инде сыра уртлап куясың. О-о-о! Кайчакта ашауны да бәхет дияргә була.

Марсель Галиев сөйләп бетергәннән соң гына күтәрелеп карый, әмма Нәбирәнең йөзендә әллә ни көнләшү-кызыксыну чаткылары күренми. Селедка ашау турында хатын-кызга сөйләгән мин җүләр, дип үкенергә генә кала.

Икенче атнаның дүшәмбесендә эшкә килгәч, Нәбирә, очынып килеп, Марсельнең күкрәген йодрыклый-йодрыклый башлый:

— Син сволочь аркасында бер атна буе кеше була алмаган идем! — ди. — Иремнән атна буе селедка эзләттердем. Ниһаять, кичә тапты. Кара ипи алып, бәрәңге пешереп, суган турап, сырадан кала нәкъ син әйткәнчә утырып ашадым.

Бу хәлгә җиде-сигез еллар уза. Бервакыт Марсель Галиев белән Нәбирә Гыйматдинова Язучылар берлегенең капка төбендә очрашалар. Төш вакыты икән.



Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 2, 1977

– Торбаның бу өлешен алыштырырга туры киләчәк!



Илдар ӘХМӘДИЕВ, «Чаян» № 13, 1976

– Меню биргән идем, ә ул аңа имза куйды!

— Беләсеңме, бүген мин ни пешердем? — дип, Марсель Галиев тәмләп сүз башлауга, Нәбирә, чебен кугандай, кулларын селки-селки:

— Сөйли күрмә, берүк сөйли күрмә! Ике йомырка гына калган иде өйдә, шуны пешерергә дип кайтып бара идем, — дип, йөгерә-атлый китеп бара.

— Нәбирә! — дип кычкыра Марсель Галиев. — Йомыркаңа паприка-кетчуп ягып аша.

Нәбирә, туктап, борылып карый да рәнҗегән тавыш белән:

— Их, сволочым, йомырканың да тәмен харап иттең, кетчуп юк иде бит минем, — дип, канатын салындырган кош сыман сүлпән генә китеп бара.

Шуннан бирле Марсель Галиев, ашау турында сөйләп, кешеләрне “җәзаламаска” була.

Александр СЕРГЕЕВ





• • •

Ире хатынының сөяркәсе – таза егет белән яткан чагында кайтып керә. Чандыр ир караватирәли чабып йөри һәм кычкыра:

– Әгәр дә пычагым булса, мин сине суяр идем! Әгәр пистолетым булса – атып үтерер идем!

Егет җавап бирә:

– Синең хәзер мөгезләрең бар – әйдә, сөзеп үтер!

Заһир ХӘКИМОВ



Әкияткә өстәмә



Эльвира ДЫШАЕВА



Виктор ФЁДОРОВ



Илдус АЗИМОВ



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хатыны – иренә:

– Безгә кичекмәстән пәрдә сатып алырга кирәк!

– Нигә?

– Безнең каршыда яшәүче ир кеше мине шәрә килеш күрергә мөмкин...

– Кадерлем, әгәр ул сине шәрә килеш күрсә – үзе пәрдә сатып алачак!

• • •

– Әйт әле миңа, син кайда булдың?!

– Матурлык салонында!

– Ник, ул эшләми иде мәллә?

• • •

Авылдан килгән әтисе белән улы “Аккош күле” балетын карарга дип театрга баралар. Балетның кызган чагы. Улы – әтисенә:

– Нигә алар аяк очларында йөриләр? – ди.

– Белмим шул, улым. Аккошлар бик күп – ишегалдын “пычратып” бетергәннәр, күрәсең...

• • •

Әбиләр эскәмиягә утырганнар да губернаторның ришвәт алу-алмавын “чәйнәп” утыралар. Яннарыннан күршеләре үтеп бара: “Бераз түзик инде, әбекәйләр, тиздән белербез: әгәр губернатор урынына берәрсен хөкем итсәләр – утыртырлар, әгәр кесәсенә салган булса – чыгарырлар”.

• • •

Одесса буйлап, ике малаен җитәкләп, яһүди әнисе бара. Аңа танышы очрый:

– Саумысыз, Сара Абрамовна! Нинди матур балалар! Ничә яшь инде боларга?

– Юристка инде алты, ә бухгалтерга дүрт кенә.

• • •

“Ля мур пердю” – французча – “Мәхәббәт үтә”. И Ходаем, ничек матур яңгырый икән!..

• • •

Түрәнең вәкаләт срогын шундый итеп корырга кирәк – ул шул чорда үзенә хәтле эшләгән түрәнең “Лаеш шулпа”сын чөмереп өлгерүен, ә үзе яңасын пешерергә өлгерми калсын.

БЕР ФИКЕРГӘ — ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Ленин әйткән: “Урыслашкан милләт вәкиле урысның үзеннән дә яманрак кылана”.

Алмаз Хәмзин: Дөрес. Урысның үзен дә чиста урыс түгеллеген әйтеп үткәндә, бу версия тагын да ныграк катлаулана. P. S. Ленин үзе дә...

Р. Н.: Кеше — ике аяклы бүре?..

А. Х.: Килешәм. Хуже...

Р. Н.: Үлүчеләр арта барган саен, зиратлар һәм кабер казучылар байый бара.

А. Х.: Ил хәерчеләнгән саен, банклар, кибетләр, аптекалар... күбәя.

Р. Н.: Көче белән “исергән” дәһшәтле коралллар берзаманны үзеннән-үзе иблискә әверелә!

А. Х.: Шул коралларны “эшкә” җигәргә әзер торучы иблис — кеше җир йөзендә яши.

Р. Н.: Начальство белән “начарство” булмавың хәерлерәк.

А. Х.: Куштанланып, “ыштансыз” яшәве дә начар.

Р. Н.: Дөньяда Ходай тарафыннан онытылган авыллар һәм кешеләр дә була.

А. Х.: Ходайга сылтама, авылда Ходай яшәми, кеше Ходай түгел, моңа үзләрен Ходай урынында күргән фиргавен — президентлар гаепле.

Р. Н.: Онытылып калган кичәге сыра — иң тәмлесе!

А. Х.: Ходай акыллары бар үзеңдә, Рашат дус!

Александр КОСМЫЛИН



Эрнест ДЫШАЕВ



Антон МАКУНИ

Булышчы

— Тукта! Кулларыңны күтәр! — диде Кәримгә подъездга керү белән нииндидер ир.

— Нәрсә?!

— Кулларыңны күтәр, — дип кабатлады билгесез адәм, аптырап калган Кәримгә пистолетын төбәп.

— Кулларым буш түгел… — диде Кәрим.

— Нәрсә белән?

— Нәрсә белән, нәрсә белән, сумкалар белән!

— Ә аның эчендә нәрсә?

— Известь белән замазка, — диде Кәрим. — Ремонт ясарга керештем…

— Аңлашылды, акчаң бармы?

— Нинди акча?! — Кәрим үпкәсен белдерде. — Ремонт ясыйм бит! Ап-ачык әйтеп торам.

— Әйе-е-е, — дип сузды сүзен бандит, пистолетын төшереп. — Ремонт — бик җаваплы эш! Нәрсә булса да башка әйберең бармы?

— Тартырга бирергә булдыра алам, — диде кызганыбрак Кәрим тегене. — Мин ни… фильтрсызны гына тартам. Ярыймы сиңа?

— Кадалып китсен, бир, әйдә! — талаучы коралын кесәсенә тыгып куйды да сигаретны алды.

— Ремонтны кем белән ясыйсың соң?

— Берүзем. Кем миңа булышсын? Менә ваннага плитә җәяргә кирәк, ә мин ничек эшлисен белмим…

— Кит аннан? — дип гаҗәпләнде җинаятьче. — Плитәне җәя белмисеңме? Нәрсәсе бар аның!

— Белмим шул, — диде кабатлап Кәрим, — асылыныйм мыни инде?

— Ә мин элеккеге штукатур-плитәче, — дип әйтте дә бандит, ачудан тәмәкесен идәнгә ташлап: — Әйдә, киттек! — диде.

— Кайда? — Аптырап сорап куйды Кәрим.

— Кайда, кайда, сиңа — ваннага плитә җәям, бүген инде берәүне дә талап булмас, — дип кулын селтәде җинаятьче.

— Минем бит акчам юк!


— Ярар, йөз грамм салып бирерсеңме? Мин бүген бу талау-нитү белән эт кебек туңып беттем!

— Мин сиңа икейөзне салып бирер идем дә, — диде Кәрим нишләргә белмичә, — ләкин…

— Курыкма, — дип елмаеп юатты ул Кәримне, — таламам! Юньле эшне сагындым мин, аңлыйсыңмы? Юньле эшне!

Һәм аптырап торган Кәримнең кулыннан сумкаларын алып, күтәренке кәеф белән баскычлар буйлап өскә атлады.

Сергей АНДРИАНОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Яшәгән, ди,
бер патшалыкта
гади бер чиновник –
Мөдәррис Иваныч.
Көнен төнгә,
төнен көнгә ялгап,
халыкка
хезмәт иткән, ди, бу...

5
10
20
30

Беркөнне кич белән Мөдәррис Иваныч «хезмәт хакы» алган,
ә иртән намуслы хезмәте өчен алган акчасын
санап карарга булган, ди...

50
60
100!
Тук-тук
Ызначит,
100 тапкыр
бишәр мең...

Тә-ә-әк... Ярты лимон...
Чәй китер әле...
Лимон белән эчәсе
килеп китте...

Менә!

– Төшкә кадәр булмыйм... эш белән... киңәшмәгә киттем... главкага...

Кая
барабыз,
шеф?


Әйдә, башта бүлнискә –
тёща янына,
аннары колледжга
малайны алырга,
аннан соң өйгә –
әбәткә...

ПАЛАТА № 6

Килгәнең өчен
рәхмәт!
Менә, операциягә
әзерлиләр.
Анестезия
һәм наркоз
мәсьәләсен
хәл итәргә
була,
диләр...
Игътибар,
кайгырту
белән дә...

АНЕСТЕЗИ

Бөтенесе дә
менә дигән
булачак...



Вячеслав **БИБИШЕВ**

Ринат БӘШИРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО





БЕЛЕМЕҢ КОРЫ КУЫК, ДУСТЫМ!

Хөрмәтле редакция! Халыкта югары уку йортларында алган белемнең сыеклыгы турында бик күп мәзәк йөри. Мин дә үз өлешемне кертергә булдым. Юрист булып эшләгәнлектән, яныма киңәш сорап яшь кенә бер егет килде. Максаты — эшмәкәр булу. Әлеге егеткә сорау бирәм: сез дәүләт өчен казнага нинди салым түләүне сайлыйсыз, гадиләштерелгән яисә керем хисабына кергән бердәм салым түләүнеме? “ИП” шәхси эшкуар булырга җыенган егет берни аңламый аптырап калды. Бухгалтерия, тәэмин итүчеләр, үзкыйммәте, маркетингка кагылышлы сораулар бирә башладым. Кызганыч, ләкин булачак эшмәкәр нәрсә турында сүз барганны аңлый алмады.

Иң гаҗәбе: булачак эшмәкәр икътисад институтын тәмамлаган яшь белгеч булып чыкты. Биш ел дәверендә лекцияләр тыңлап, имтиханнар тапшырып, диплом яклап, гади генә клиентка чек язып бирү, касса аппаратын кайдан алырга һәм аның белән ничек эш йөртергә, касса кирәкме-юкмы, канун кыйссаларына таянып нәрсә эшләргә ярый, ә нәрсә ярамый икәнен дә белми икән.

Күрәсең, әлеге егет биш ел уку вакытын юк-бар нәрсәләр белән кызыксынып бушка үткәргән. Кызганыч, студентларны теория белән дыңгычлап, тормышта иң кирәкле гади генә белемне бирми калалар. Бәлкем, шуңа да икътисад “белгечләре” сату-алу агентлары, урам чатларында реклама кәгазе тарату белән мәшгульдер. Кайберләре әле дә булса эш таба алмый интегә...

Р. МӘХМҮДОВ

КАЗАН

ЧАРАСЫН ТАБАРСЫЗ...

Кадерле Чаян! Безнең авыл башкалабыз Казан шәһәренә тоташып тора диярлек. Бер карашка, көндәлек тормышта кулланыла торган шартлар да уңай һәм гади булырга тиештер кебек. Әлбәттә, авылга газ кертелде. Тик су белән генә азапланабыз. Бигрәк тә К. Маркс урамында яшәүче халыкка урамдагы колонкадан ташырга туры килә. Анысы да әле эшләсә эшли, эшләмәсә – юк!

Нишләп безнең урам гына мондый "бәхеткә" лаек булган соң? Бик күп шикаятьләр дә язып карадык, ләкин үтенечләребезне исәпкә алмыйлар. Авыл җирлеге вәкилләренең моңа җавабы кыска: "...Кайбер кешеләрнең үз скважинасы бар". Ә калганнар нишләргә тиеш?

Бер сүз белән әйткәндә: су булмаячак, ләкин түзегез!

К. Маркс урамында яшәүчеләр.

ЮГАРЫ ОСЛАН районы,
ТҮБӘН ОСЛАН авылы.

ӨМИДӘДӘН КАЙНАР СӘЛАМ!

Чаян дус! Күптән түгел күрше кибеттән ААҖ "ПК Фабрика качества" пилмәне алырга булдым. Бәясе дә кыйммәт түгел, тәме дә ярап тора. Кайнап торган суга пилмәннәрне салып җибәрдем. Ләкин пилмән урынына ниндидер кәгазь кисәкләре калкып чыкты. Язуы да бар: "Өмидә". Интернеттан озак актара торгач, хатынкыз исеме икәнен аңладым. Фабрикага хат яздым. Кем белә, бәлкем, серле һәм таныш булмаган Өмидә әлеге пилмәнне үзенә калдырган булгандыр? Җавап озак көттермәде. Әлеге язмалар үзенең эшчеләрен күзәтүче мастерларга языла икән. Ә кәгазь язма пилмән тутырган эшченең саксызлыгы аркасында эләккән булып чыкты. Бер дә курыкмый ашарга киңәш итүләре мине бераз тынычландырды.

Ашавын ашадым, тик менә күңелсез хәл генә хәтергә уелып калды. Ник дисәң, упаковка сыйфаты өчен җаваплы мастер шундый "сәлам" хатлары калдырсын әле...

КАЗАН

Г. РӘШИДОВА

МЕНӘ СИҢА МӘ!..

Хөрмәтле редакция! Күптән түгел безнең микрорайонда 12 нче гимназияне ачтылар. Уку бинасын ничек кирәк шулай матурладылар: зур койма белән әйләндереп алдылар, агачлар утырттылар, җәяүлеләр өчен уңайлы тротуар да ясалды. Бик зур көч түгелде, ник дисәң дә югары дәрәҗәле кунаклар чакырулы иде ачылыш тантанасына. Ыгы-зыгы тынгач, мәктәп ачылгач, әлеге мактаулы мәйданда төзелеш эшләре кабаттан эшмәкәрләр тарафыннан күзгатылып җибәрелде. Тротуар өстендә, мәктәптән ике адым да атламас җирдә зур кибет төзеделәр. 85нче йорт почмагына урнашкан "шәһәр йөзен ямьсезләндереп торган" газета киоскын алып ташлап, аның урынына әлеге киосктан да артык җире булмаган яшелчә кибете төзеп куйдылар. Күп тә үтмәде, тагын бер яңа кибет калкып чыкты. Аннан "Үзбәк кухнясы" һәм "шаурма"га да чират җитте...

Соңгы ике бинаның даими клиентлары артык мәдәният белән дус булмаганлыктан, көне-төне әлеге бина янында тавыш-гауга халыкның тынычлыгын югалтырга мәҗбүр итте. Аш-су калдыклары якындагы йорт контейнерларына актарыла, ә һава суырткычтан чыккан "шаурма" исләре көнчыгыш кулинариянең әче-төче исен бөтен урамга аңкытып тора. Кыскасы, әлеге мәйданны яулап алган эшмәкәрләр маташтыруы безнең йокыларыбызны качырды, тынычлыгыбыз югалды һәм нерв күзәнәкләре таркалуына китерде.

Декабристлар урамының 85, 87, 89-б йортында яшәүчеләр.

КАЗАН

Илдар НӘФИЕВ



Александр АЛЁШИН







Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хастаханәдә.

— Доктор, мин иелеп, кулларымны аска сузам, бер аягымны күтәрәм, аннан соң төшерәм, икенчесен күтәрәм, төшерәм, бөгеләм һәм кулларымны билгә хәтле күтәрәм, берочтан җиңелчә генә сикереп куям, шул вакытта минем аркамда чыдап булмаслык авырту барлыкка килә.

— Нишләп соң сез шушы яшегездә шундый катлаулы күнегүләр ясыйсыз?

— Сезнеңчә, чалбарымны мин ничек киярга тиеш соң?

• • •

Теге дөньяда ике ир очраша:

— Син ничек үлдең?

— Туңдым. Ә син ничек?

— Көлүдән үлдем.

— Ул ничек була инде?

— Мин сөяркә белән идем. Ишектә – кыңгырау. Нишләргә белми аптырап калдым. Ире кайткан. Ул иренә ишекне ачты да кулына чүп чиләген тоттырды. Мин шул арада чыгып шылырга өлгердем. Өйгә кайтып ишекне ачуга, хатын миңа да чүп чиләген сузып тора. Мин шундук аңлап алдым, фатирыма бәреп кердем дә бөтен җирне актарып ташладым, ләкин беркемне тапмадым. Диванга утырдым да үземнән көлә-көлә үлдем дә киттем.

— Җүләр! Суыткычны ачып карарга иде – икебез дә исән калган булыр идек.

• • •

Одессага килгән берәү мондагы кешегә:

— Миңа сездәге юмор шулхәтле ошый!

— Әйтсәм әйтим инде, юмор шундый буламы инде?! Бөтен юморны яһүдләр үзләре белән Израильгә алып киттеләр! Бары тик көлкесе генә калды!


• • •

— Ни өчен байлар озак яшиләр?

— Алар кулларына гимнастика ясыйлар.

— Нинди?

— Акча саныйлар. Бу күнегү буыннардагы сызлауны бетерә, кан басымын рәтли, баш авыртуын туктата, күрү сәләтен көчәйтә, аппетит әйбәтләнә, килешкилбәтне яхшырта, кием-салым үзгәрә һәм яшәү-тору шартлары гаҗәпләнерлек үзгәрә.


Максим СМАГИН





Валерий ТАРАСЕНКО


Виктор БОГОРАД

Тишек көпчәк

Максим СМАГИН





Ике машина йөртүче сөйләшә:

– Ишеттеңме? Бездә түләүле юллар төзергә җыеналар, ди. Алар түләүсезләргә караганда ике тапкыр арзанрак булачак.

– Ничек инде?

– Түләүле юлларда юл инспекторлары булмаячак.



Фирдәвес ЗАРИФ



Салиханың җырчы буласы килә иде. Җырчының да ниндие әле — йолдыз. Әмма йолдыз булам дип сәхнәгә атылып чыгып булмый бит инде.

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, чарасы да табылды тагын: ахирәтенең дус кызының дусты җырчы икән ләбаса. Телефон аша сөйләшеп, очрашырга да сүз куештылар. Очрашуга ахирәтенең дустының дусты Венера белән китте.

— Сылукай. Эстраданың иң якты йолдызы! — дип тәкъдим итте ул аны Салихага. Аннары, аңа борылып: — Ә бу Салиха була, — диде.

— О, сәлам, сәлам! — дип елмайды Сылукай. — Хәлләр ничек?

Ул җавап бирергә дип авызын ачкан гына иде, аның өчен Венера әйтеп өлгерде:

— Салиханың хәлләре сиңа бәйле, Сылукай. Эстрада җырчысы, синең кебек йолдыз буласы килә аның.

— Шулаймы? Ярый, постараемся. Только башта сиңа исемне үзгәртергә туры килер. Салиха ничектер старомодно. Әйдә, Сальеро дип куябыз.

— Үзебезчәрәк булмасмы икән? — дип карышасы итте Салиха.

— Вообще-то, да. Алайса Сәлирә булырсың. — Сылукай, чытыкланып, сәхнә торышы алды: — Сәхнәдә — эстраданың яңа йолддызы Сәлирә! Алкышлар белән каршы алыгыз!

— Шәп, шәп, — дип кулларын чәбәкләде Венера. — Син гений, Сылукай!

— Ярый, монысы булды, — диде Сылукай ирен чите белән генә елмаеп. — Хәзер инде кыска итәкле күлмәк кирәк. Аякларың шәп синең, просто прелесть булачак.

— Юбка гына ярамасмы икән, Сылукай? — дип кыенсынып кына сорап куйды Салиха-Сәлирә.

— Була, юбка да пойдет. Анда инде кендегеңә пирсинг кирәк булыр.

— Идея! — дип бер урында сикеренде Венера. — Минә бу класс, ичмассам. Бөтен ирләрнең күзе синдә булачак. Аяк тибеп кул чабачаклар.

— Ни бит, ирем нәрсә әйтер бит.

— Ерунда! — диде Сылукай, исе китми генә. — Үзем сөйләшермен. Давай телефон номерын. Бүген үк эшенә шалтыратам.

Киемнәр алынды, кендек тә, тишелеп, энҗеле пирсингка ия булды. Сылукай да сүзендә торды: "Ильшатигың белән сөйләштем, барысы да о-кей. Суббота көнне Венера белән продюсерга тыңлауга барырсыз. Үзем авырып торам әле, сиңа да яткан килеш кенә шалтыратам", — диде.

Тыңлаулар әйбәт узды. "Тавышың бар, калганын җайларбыз", — дип, канат куеп озатты продюсер Салиха-Сәлирәне.

Кич кенә кайтам дип чыгып киткән Салиха көндезге өчтә фатирының ишек төбендә иде инде. Кыңгырау төймәсенә басып тормыйча, ишекне үзе ачып керде. Юыну бүлмәсеннән ишетелгән су тавышына исе китмәде аның: "Илшат юынырга кереп киткәндер", — дип уйлап куйды. Кухняга кереп, ашарга әзерләргә керешкән генә иде, хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Ильшатик! Мин проголодалась. Берәр нәрсә әзерлә әле. Любимый, син кайда?

Алгы якка чыгуга, көтелмәгән хәлдән катып калды Салиха. Аның каршында ялангач тәненә Салиханың халатын ябынган Сылукай басып тора иде.



Валентин ДУБИНИН

Рашат НИЗАМИ

"МИССИС"ЛӘР

Илләр тетри, сулар котырына...
Ә сәхнәдә — чәчәк, хуш-исләр.
Афәт җилләреннән коткарырмы
Халыкара
Бәйгеләрдә җиңгән "мисисс"ләр?

ИСӘП

Тимерчедән тимер исе килә,
Итекчедән — җилем исләре.
Аракыдан шайтан исе килә —
Бөтенләйгә
Кул селтәргә аңа исәбем!

БҮЛӘК

Тормыш безгә күпне бүләк итә, —
Сөю-югалтулар ачысы...
Берзаманны:
"Минә сиңа картлык", — диеп дәшсә,
Бу "бүләк"тән ничек качасы?

РОБАГЫЙ

Бугазга баса замана ачысы,
Житми кайчак хакыйкать тамчысы.
Мәче тычканны уртәгәндәй итеп,
Баш очында
Уйный-шаяра язмыш камчысы.

Михаил ЛАРИЧЕВ



Александр СЕРГЕЕВ



АРЧА ПОЕЗДЫНДАГЫ ӘҢГӘМӘ

Элек Казанга барганнар
Арчалар пар атларда.
Хәзер билет бесплатный
Алтмыштагы картларга.

Кеше юлда ялгыз булса
Синең белән киңәшә.
Минем янымда бер апа
Бик акыллы сөйләшә.

60 яшь бирергә була,
Минемчә, бик азына.
Бик чибәр булгандыр үзе
Гомеренең язында.

— Апа, кайлардан кайтасыз?
Уңдымы соң юлыгыз?
Әйбәт каршы алдымы соң
Казандагы кызыгыз?

— Үз өемә кайтам, улым,
Арча ягы салага.
Каз суеп кызыма бардым
Казан дигән калага.

Киявем артист икән бит —
Бер еллыгын уздыра.
Әле акча биргәне юк,
Кызымныкын туздыра.

Инженер бит минем кызым —
Казанның горгазында.
Хезмәт хакы алып эшли,
60 мең — иң азында.

Бәлки, улым, очрашырбыз —
Баргалыйм мин шәһәргә.
Артист булмасаң, килеп чык
Син дә безнең тирәгә.


Бездә кызлар шундый чибәр —
Башың-күзең әйләнер.
Әгәр Ходай насыйп итсә,
Чәчең чәчкә бәйләнер.

Юллар кыскарып китәләр,
Кеше белән киңәшкәч.
Яшьлегемә кире кайттым,
Синең белән сөйләшкәч.

Артист турында сөйләмә —
Кешеләр белмәсеннәр.
Килеп капкан инженер дип,
Кызымнан көлмәсеннәр.


Сөләйман ШАКИРОВ,
хезмәт ветераны, 80 яшь.





Иван Фёдоров беренче китап бастыручы булса, **Виктор ФЁДОРОВ** – рәсемнәрне иң күп бастыручы. Чиләбе рәссамы бу өлкәдә рекорд куйган. 75 яше тулуга ул 75 мең карикатура ясаган, һәм бастырып чыгарган. Аның сүзенә караганда, ул аларның яртысы «Чаян»да дөнья күргән. Бу вернисаж армас-талмас Виктор Михайловичның рекордына тагын бер кечкенә өстәмә булыр.







Виктор ФЁДОРОВ







ЧуАр пресса

СОҢГЫ ӨМЕТ

70 яшьлек америкалы Лоурен Риппл банкка килгән, пистолетын чыгарып акча таләп иткән. Кассада акча бик күп булмаган – барлыгы өч мең доллар. Акчаны алгач, пенсионер вестибюльгә чыгып, полиция килүен көтә башлаган. Лоуренс, тәртип саклаучыларны аптырашта калдырып, дөресен сөйләп биргән. Ул банкны төрмәгә утырыр өчен һәм картлык көнендә бәйләнчек хатыныннан ял итәр өчен талаган.

ЭТ ЮГАЛГАН


Эшмәкәрләр гаиләсе Сочида ял иткән. Үзләре белән алар Джулия исемле таксаларын алганнар. Эт пляжда аерым бер миссия үтәгән. Ир белән хатын су коенырга киткәндә, алар ювелир әйберләрен дүрт аяклы сакчыларының муенчагына бәйли торган булганнар. Бервакыт ярга чыккач, алар ни этне, ни миллион сумлык асылташларны тапмаганнар.

ЯНМЫЙ!

Бирменгемда яшәүче Марк Эдварс коткару хезмәтенә шалтыраткан һәм бармагында ярәшү балдагы утырып калуы турында хәбәр иткән. Составта Джоди исемле яшь хатын булган янгын экипажы озак көттермәгән. Марк аның каршысында бер тезенә тезләнеп тәкъдим ясаган. Джоди ризалык биргән, чөнки алар инде алты ел бергә яшәгәннәр һәм аларның ике балалары булган. Өлгер янгын сүндерүчеләрдән аермалы буларак, кияү бик озак вакыт өйләнешергә карар кыла алмаган.

«АЮ БАЛАСЫ» ОПЕРАЦИЯСЕ

Финляндиянең Пасиль шәһәрендә автобус тукталышында плюш аю баласы тапканнар. Полиция шәһәр буйлап югалган уечыкның фотосын ябыштырып чыккан. Хуҗаны эзләргә фин газета-журналлары һәм соц. челтәр кулланучылары кушылган. Масштаблы операция нәтиҗәсендә, аю баласының ике яшьлек хуҗасы табылган, һәм аңа тантаналы рәвештә плюш дустын кайтарганнар.



Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр




ЗАБРАВСКИЙ (Польша)



Генри БЮТНЕР (Германия)





Мирослав БАРТАК (Чехия)



Дэн ПИРАРО (Англия)



Иржи СЛИВА (Чехия)



Граняк (Польша)

Cartoonblues. com., BizarroComic.Blogspot.com



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Грузин кешесе ашыгып вокзалдан чыга да татар әбисеннән сорый:

– Она таки ушёл.

– Кем ул она?

– Поезд...

– Поезд бит ул “она” түгел, “он”!

– Вот еще один умный нашёлся. Он, она... Что я эту паровоз буду между колесов рассматривать?

• • •

– Кадерлем, синең структрурировать ителгән углеродка мөнәсәбәтең нинди?

– Син мине үзеңнең интеллектуаль кыланышларың белән шулхәтле туйдырдып бетердең! Теләсәң нишлә, ник шунда шайтаныңа олакмыйсың!

– Аңлашылды, шулай дип язып куябыз: туган көнеңә аласы бриллиант балдак – шайтанга...

• • •

– Сез мине шундый озак озаттыгыз, бәлки, чәй эчәргә керерсез?

– Рәхәтләнеп. Тик башта аптекага кереп чәй эчәргә бирәр нәрсә алыйм әле.

• • •

Клиент – страховой агентка:

– Сезнеңчә, бакчам яна калса, бу полиста язылганча акча алачакмын, әйеме?

– Әйе, әгәр дә үзегез ут төртмәгән булсагыз...

– Ә-ә! Уйлаган идем аны, монда ниндидер хәйлә бардыр дип!

• • •

Өйләнгәнче сөтне суыткычка дөрес куймау турында шикләнми дә идем.

• • •

Офисның җыештыручысы кочләнгән. Шикләнүчеләр тоткарланган, суд бара. Бәлагә дучар булганнан сорыйлар:

– Нишләп сез качмадыгыз?

– Кая качыйм? Юылган җирдәнме?!

• • •

Судта.

– Шаһит, сез чәршәмбе – 2016 елның 16 мартында 11 сәгать 42 минутта нәрсә эшләдегез?

– Мин кулыма календарь тоткан килеш сәгатькә карап утырдым.

• • •

– Улым, исеңдә тот: башың белән уйла, йөрәгең белән ярат, арт саның белән той... Ләкин иң әһәмиятлесе – бернәрсәне дә бутама.

Евгений ОБУХОВ

БАЛЕТ ҖЕНЕ КАГЫЛГАН ВӘЛИТ

Безнең авылдагы тракторчы Вәлит белән әллә нинди көтелмәгән хәл килеп чыкты бит әле. Ул гадәти булмаган юнәлештәге егет икән бит. Кайсыдыр шәһәрдә шундыйларга күнегеп беткәннәр, ди, анда халык та күп — сизелми дә. Кайдадыр Гаиф кебекләр модада, ди, дә бит... Әле ул, урысча әйтмешли, культивируется икән, мәсәлән, алыйк Зур театрны!.. Авыл җирендә барысы да күз алдында, бернәрсәне дә яшереп булмый.

Бер сүз белән әйткәндә, авыл җирендә Вәлитнең мондый гадәтсезлеге ачыкланды берзаман: аның бу хатын-кыз булыбрак кыланып йөрүе балет яратудан икән бит. Юк, “Балет” конфеты түгел. Без, ирләр, аны кайчагында кызыл аракыдан соң кабып куйгалыйбыз. Ул тегенди – тыгыз трико киеп, оялмыйча сәхнә буйлап кызларны күтәреп йөри торган спектакль икән.

Без, әлбәттә, бу нәрсәгә берни аңламаган аңгыра түгелләр, балетның матурлыгын чамалыйбыз: әйтик, андагы аяклар, күкрәкләрне әйткән дә юк, кәнишне, булса инде әгәр берәрсендә. Тора-бара тракторчы Вәлитебезгә анысы бик үк мөһим түгеллеге ачыкланды. “Сез, — ди ул, — биюләрнең һәм музыканың гүзәллегенә чумыгыз!”

Үзе бит, үзе кыр буйлап трактор йөртә — моторын сүндерә дә кабинасыннан чыгып, кулы белән чәчләренең бер кырыена тотына һәм балеттагыча аягындагы итеген күтәрә, әйтерсең, шомырт агачына килеп эт “йомышын” үти. “Балетсыз яши алмыйм, теләсә нәрсә әйтегез!” — ди.

Шуны исбатлау өчен булды микән — кияүдәге укытучы кызның башын әйләндерде. Без башта аны өйләнер өчен йөри дип уйладык. Алай булып чыкмады. Ул кызны кояш баер алдыннан күл кырыена алып чыккан да, әй йөртә күтәреп болын буйлап, әй йөртә!..

“ Бу, — ди, — безнең па-де-де һәм виртуозная кода...” Ә тегесе, белсәгез иде, көлә дә көлә, аякларын дырылдата.



Вячеслав ШИЛОВ


Ире белеп торды, ләкин Вәлиткә бер сүз әйтмәде, хәтта тырнак белән дә чиертмәде. Ул ычкынганнан ни чыккан: аның справкасы да бар шундыйлыкка. Анда акка кара белән язылган: “Опера һәм балет театры дип. Билет бәясе 1000 сум”. Уйлап карагыз: мең штук өч сәгать эчендә кап-караңгы залда, бер тамчы эчмичә. Шулай, мужикның башында мәкинә!

Ул театрга керергә шәһәргә дә барып карады. Алмадылар. Әллә нинди этлекләр уйлап таптылар ди алмаска — примнар, лауреатлар. Алар балетта мин ишетмәгән футэлар сорыйлар — утыз ике тапкыр бөтереләләр. Вәлит безгә кызган баштан, кырык тапкыр шуны эшләп ыргыттым, ди. Алар әллә көнләштеләр, ди...

Без бит инде, авылдагылар, аның ычкынганлыктан алдарга осталыгын беләбез! Кая аннан кырык футэ, безнең үз күзебез белән күргәнебез булды: ул бертөсле фигураны утыз биштән артык ясый алганы булмады...

Менә бит нинди бәла килеп чыкты әлеге кеше белән!

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Спортта иң мөһиме нәрсә?

2. Туганнарыгызның күпме икәнлеген белү өчен нишләргә?

3. Хәвеф-хәтәрсезлектән саклану техникасы — сәнгатьме әллә фәнме?

4. Ирләр һәм хатын-кызлар ни өчен спортзалга йөриләр?

5. Авылда эчми торган ирләрнең хатыннарын ничек дип атыйлар?

6. Хатын-кызлар сезне тыңласыннар, эндәшмәсеннәр һәм куркып торсыннар өчен нишләргә кирәк?

7. Бик кайнар чәйне ничек итеп суытып була?

ЖАВАПЛАР

1. Анализлар. 2. Диңгез буенда йорт сатып алыгыз. 3. Ул дин. Аңа ышанмаска мөмкин, ләкин гореф-гадәтне үтәү мәҗбүри. 4. Бер нәрсә өчен генә. Күз явын алырлык гүзәл кыз сылулыгына ия булуга ирешү теләге белән. 5. Тол хатыннар дип. 6. Теш табибы һөнәре буенча эшләү. 7. Бик җайлы гына. Бер минутка гына Интернетка керәсең, һәм... онытыласың!.. Чәең суынды дип уйла.

Сынамышларны Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 15 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **“МИШӘ БУЙЛАРЫ”, “КОШЛАРГА”.**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. ГАРИПОВА (Сарман),
Г. ГАТИЯТУЛЛИНА (Саба р-ны, Сатыш ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
М. ХАЛИКОВА (Яңа Чишмә р-ны, Акъяр ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Сатыш авылыннан **Гөлия ГАТИЯТУЛЛИНА!**



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 16 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа

16+

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066



Алексей МАМАЕВ



Виктор ФЁДОРОВ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлады. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»ны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга – П2438, ә русчасыныкы П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!

Уйна да, уйла да!

Яшь рәссамга Лотфулла Фәттаховның «Сабан туе» картинасыннан копия ясарга кушканнар. Ул анда үз белдеге белән ун деталь өстәгән. Шуларны табыгыз.



РӘСЕМНӘРДӘ 10 АЕРМА ТАП







Карикатура осталары

Майк ВИЛЬЯМС (Бөекбритания)






Майк ВИЛЬЯМС – танылган инглиз карикатурачысы. Аның рәсемнәре дөньяның бик күп басмаларында басылып чыккан. Хәзер алар менә «Чаян» битләренә дә килеп җитте.





– Карале, нинди гаҗәеп бизәнү әйбере!



– Мин моны эшләдем! Мин ярымфиналга уздым!



Chisbeetles. com

